# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең Вәрәшбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында**

02 апрель 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның 2 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең Вәрәшбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә ризамы" дигән сорауны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Вәрәшбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,00 (бер мең биш йөз сум) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750,00 (җиде йөз илле сум) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтергә ризамы:

1). Торак пункт территориясен төзекләндерү.

- Кооператив урамында спорт мәйданчыгы төзелеше;
- төзелеш материаллары сатып алу һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү;
- үлән чабу;

2). Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

- урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү. Беренче Май, Кооператив һәм Комсомол урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу, урнаштыру;

3). Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:

- су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- су башнясын караучыга килешү буенча хезмәтләре өчен түләү;
- су башнясына хезмәт күрсәтү;
- анализга су алу .

4). Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

5). Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм

мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзекләндерү , ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

- Кооператив урамындагы һәйкәл территориясен төзекләндерү.

6). Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- Комсомол, Кооператив урамының асфальт өлешендәге чокырларны ремонтлау.

- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында вак таш белән капланган юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу , тракторчыга хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары);

- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында кышкы һәм җәйге вакытта авыл эчендә юлларны тоту(штаттан тыш хезмәткәргә (тракторчыга) хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары өчен түләү, «Беларус " тракторы өчен запас частьләр һәм өстәмә җиһазлар сатып алу);

- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында җәйге вакытта юлларны грейдирлау.

7). Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү:

- "Салкын Чишмә", "Тәпти", "Исрафил "чишмәләрен төзекләндерү.

8). Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар төзү:

- зираттан каты коммуналь калдыклар чыгару;

- койма буяу;

- үлән чабу (ягулык-майлау материаллары, бензотриммер сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);

- карт агачларны кисү

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 165 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 92, бу 55% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 90 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 2 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең Вәрәшбаш торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең Вәрәшбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,00 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750,00 (җиде йөз илле) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтергә:

1). Торак пункт территориясен төзекләндерү.

- Кооператив урамында спорт мәйданчыгы төзелеше;

- төзелеш материаллары сатып алу һәм халыкның күплән ял итү урыннарын төзекләндерү;

- үлән чабу;

2). Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

- урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү. Беренче Май, Кооператив һәм Комсомол урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу, урнаштыру;

3). Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:

- су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- су башнясын караучыга килешү буенча хезмәтләре өчен түләү;
- су башнясына хезмәт күрсәтү;
- анализга су алу .

4). Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

5). Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзекләндерү , ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

- Кооператив урамындагы һәйкәл территориясен төзекләндерү.

6). Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- Комсомол, Кооператив урамының асфальт өлешендәге чокырларны ремонтлау.
- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында вак таш белән капланган юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу , тракторчыга хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары);
- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында кышкы һәм җәйге вакытта авыл эчендә юлларны тоту(штаттан тыш хезмәткәргә (тракторчыга) хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары өчен түләү, «Беларус " тракторы өчен запас частьләр һәм өстәмә җиһазлар сатып алу);
- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында җәйге вакытта юлларны грейдирлау.

7). Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү:

- "Салкын Чишмә", "Тәпти", "Исрафил "чишмәләрен төзекләндерү.

8). Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар төзү:

- зираттан каты коммуналь калдыклар чыгару;
- койма буяу;
- үлән чабу (ягулык-майлау материаллары, бензотриммер сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- карт агачларны кисү

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгы З.З.Галиева